| | | |
|---|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Глава Верхне-Чершилинского сельского поселения Сармановского муниципального района** | | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль районының Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.11.2023 № 4

2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлегенең Югары Чыршылы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясы нигезендә карар итәм:

1. Югары Чыршылы авылы мәдәният йорты бинасында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2023 елның 17 ноябренә 14 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Югары Чыршылы авыл җирлегенең Югары Чыршылы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I төркем инвалидларыннан, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган затлардан, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш 2024 елда 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

1) Югары Чыршылы торак пунктында традицион җирләү урыннарын ремонтлау, төзекләндерү (мәгълүмат стендларын сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

2) Югары Чыршылы торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, мәгълүмат стендлары сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

3) Югары Чыршылы торак пунктында җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту (махсуслаштырылган техникага - МТЗ-82.1 тракторына хезмәт күрсәтү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу);

4) Җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын тоту (Югары Чыршылы торак пунктында кышкы вакытта юлларны кардан чистарту);

5) Югары Чыршылы торак пунктында халыкның күпләп ял итү урыннарын төзү, ремонтлау (балалар мәйданчыгы территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, мәгълүмати стендлар алу һәм урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү);

6) Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (Югары Чыршылы торак пунктында янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эш өчен түләү).

«ӘЙЕ «ЮК»

3. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларына, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгару юлы белән игълан итәргә http://pravo.tatarstan.ru һәм Сарман муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында http://sarmanovo.tatarstan.ru кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Югары Чыршылы авыл җирлеге башлыгы И.Н. Камалетдинов